ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Чернышевского ул., д.23, г.Лаишево 422610

Чернышев урамы, 23 нче йорт Лаеш ш. 422610

Тел: 8-(84378) -2-52-28 Факс: 8-(84378) -2-54-34
e-mail: Ispolkom.Laishevo@tatar.ru

---

**2023 елның 30 декабре** **4165 номер**

## КАРАР

**Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Нармонка авыл җирлеге, 220503 квартал, 337 ж/к адресы буенча урнашкан кадастр номеры 16:24:220503:337 булган җир кишәрлеге территориясен чикләү проектын әзерләү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 41, 43, 45 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Уставы нигезендә, территорияләрнең тотрыклы үсешен тәэмин итү, шул исәптән планлаштыру структурасы элементларын бүлеп бирү, җир участоклары чикләрен билгеләү, капиталь төзелеш объектларын урнаштыру зоналары чикләрен билгеләү максатларында, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Нармонка авыл җирлеге, 220503 квартал, 337 ж/к адресы буенча урнашкан кадастр номеры 16:24:220503:337 булган җир кишәрлеге территориясен чикләү проектын әзерләүгә керешергә.
2. Проектның эчтәлеген Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше Кодексының 43 маддәсенә ярашлы рәвештә билгеләргә.
3. Ачык тыңлаулар (җәмәгать фикер алышулары) үткәрүне исәпкә алып, проектны әзерләү вакытын 2024 елның июненә кадәр билгеләргә.
4. Әлеге карар басылып чыкканнан соң ун дүрт көн эчендә физик һәм юридик затларга Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетына территорияне чикләү проектының тәртибе, вакыты һәм эчтәлеге турында фикерләрен җибәрергә тәкъдим итәргә.
5. Әлеге карарны “Кама ягы” («Камская новь») район газетасында, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге башлыгы А. П. Карсаловка йөкләргә.

**Җитәкче** **А.Ә. Нурмөхәммәтов**